| СОВЕТ ИСЕРГАПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСЕРГЭП АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Исергэп авылы

12 нче сентябрь 2019 г. № 101

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлегендә 18 яшькә җиткән, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, беренче һәм икенче төркем инвалидларыннан тыш, 200 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын

бер тапкыр түләүне кертү турында тәкъдим итәргә., тыл ветераннары һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

Исергәп авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Исергәп авылында яктырту;

- Яңа Баулы авылында яктырту;

3. Әлеге карар Исергәп авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш (http://bavly.tatarstan.ru/rus/Isergapovskoe.htm Исергәп авыл җирлегенең Исергәп авылы, авыл җирлеге бинасы, Совет урамы, 86А йорты адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык, Совет Рәисе

Исергәп авыл җирлеге башлыгы А. А. Әһлиуллин